# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«11» 12 2024 ел № 5560

«ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе структурасына һәм штат санына үзгәрешләр кертү турында. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ составындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 30 мартындагы 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы 2 өлеше, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы «исеме» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «муниципаль район мәгариф идарәсе (бүлеге)» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеме белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 22 ноябрендәге под-1950/24 номерлы боерыгы нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе структурасына һәм штат санын үзгәрешләр кертү турында. «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ составындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Башкарм комитетының 2022 елның 30 мартындагы 979 номерлы карарына түбәндә үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә 1 пунктны түбәндәг редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләр мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | Айга база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 20246,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 20251,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә мөдире (башлыгы) урынбасары: муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлеге;<br>Структур бүлекчә мөдире (башлыгы): муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлеге | - | - | 20329,0<br>20405,0 |

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 1.12 пунктчасын өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.12. | «Яшьлек һәм Профессионализм» күкрәк билгесе.». |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазифаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев